Зур Сәрдек авыл җирлеге Советы

КАРАР

2019 елның 28 ноябре №25

«Җир салымы турында» 2013 елның
22 ноябрендәге 32 номерлы
Зур Сәрдек авыл җирлеге Советы карарына
үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә Зур Сәрдек авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. «Җир салымы турында» 2013 елның 22 ноябрендәге 32 номерлы Зур Сәрдек авыл җирлеге Советы карарына (Зур Сәрдек авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 ноябрендәге 33 номерлы, 2015 елның 28 маендагы 25 номерлы, 2015 елның 26 ноябрендәге 15 номерлы, 2017 елның 27 июнендәге 11 номерлы, 2018 елның 9 ноябрендәге 28 номерлы, 2018 елның 29 ноябрендәге 32 номерлы, 2018 елның 19 декабрендәге 35 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) кадастр бәясеннән 0,1 процент – торак фонды һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексның инженерлык инфраструктурасы объектларына карамый торган объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокуктагы өлешләрдән тыш) яки торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) (эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланыла торган шәхси торак төзелеше өчен алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш) җир кишәрлекләренә карата;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, шулай ук Зур Сәрдек авылы җирлеге торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмати стендларда урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән соң кимендә бер ай узгач, үз көченә керә.

Авыл җирлеге башлыгы: Ф.М.Фәттәхов.

ОГРН 1021607753232
ИНН 1623001727